ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 23 от «30» 01 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 04 февралендәге 45 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешендәге 15 пункты һәм 34 статьясындагы 9 өлеше, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер оешмадан укучыларнытиешле дәрәҗәдәге мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга күчерү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2014 елның 12 мартындагы 177 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 февралендәге «Мамадыш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 45 номерлы карарына (алаг таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1 нче кушымтаның 1.1. пунктындагы «,яисә тиешле белем бирү программасы буенча дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булу срогы бетү» сүзләрен «дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуын туктату» сүзләренә алмаштырырга, «дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуын тулысынча яисә аерым белем бирү дәрәҗәләренә карата туктатып тору» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» һәм Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru// рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

0000011562

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов